**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Чияле Алан торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**10 апрел 2024 ел** **№ 14**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Чияле Алан авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан авыл җирлегендә 24.11.2023 елның 3нче номерлы гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан авыл җирлегендә 24.11.2023 елның 4нче номерлы гражданнар җыены карары турында алдан расланган карарга өстәмәләр кертергә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Чияле Алан авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә алынган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эшләр исемлегенә түбәндәге эш төрләре белән үзгәрешләр кертергә:

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Урам яктырту җайланмасы мәсьәләләре буенча кабул ителгән карарны танырга.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Б. Храбров

Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы: И.Б. Храбров